Конспет «Зоопарк» (Зурлар төркөме)

Бурычлар:

1. Тәрбия бурычы: Кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык һәм зоопаркта үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү.
2. Үстерү бурычы: Уеннар һәм тирә-юнь белән танышу барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Белем бирү бурычы: Кыргый хайваннар һәм аларның үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. Зоопарк турында белемнәрен киңәйтү.

Төп белем бирү өлкәсе: Сөйләм теле.

Интеграль белем бирү өлкәсе: аралашу, социальләштерү, сынлы сәнгать, сәламәтлек, матур әдәбият, музыка.

Методик алымнар һәм чаралар: уен, табышмак, сораулар бирү, әңгәмә, сюрприз момент, мактау.

Сүзлек өстендә эш: җираф, маймыл, арыслан, фил, вольер.

Җиһазлар: зоопарк макеты, җәнлекләр уенчыклары, рәсемнәре, җәнлекләрнең күләгәләре ябыштырылган эзләр, урман, сарай күренеше рәсемнәре, поректор, экран, “В мире животных” музыкасы , “Летчики” җырлы уен, медальённар, китап эшләү өчен материал .

Эшчәнлек барышы:

Кунаклар белән исәнләшү.

- Балалар, карагыз әле безгә бүген бик күп матур апалар кунаклар килгәннәр, әйдәгез алар белән исәнләшик., хәерле кәннәр телик.(*балалар исәнләшәләр*).

1) Маша көлгән тавыш ишетелә.

- Балалар, кемдер шаярып көлә түгелме, сез барыгызда мондамы соң? Әйдәгез әле саныйк сез 12 булырга тиешбез. (*күмәк санау*). Барыбыз да монда, кем көлде микән сөң ул?
- Балалар, карагыз әле монда, нәрсәләр соң бу?(эзләр). Әйдәгез шул эзләр буенча барып карыйбыз, бәлки сер чишелер.

2***) Эз буенча барганда Маша көлгән тавыш тагын ишетелә, экранда Маша сурәте күренә.***

- Балалар, карагыз әле безнең белән кем шаярган, танадыгызмы?(*Маша көлә*).
- Маша бит безгә бер сер алып килгән, шуны чишергә кирәк. Әллә сер менә бу эзләрдә микән, әйдәгез карыйбыз.(*карыйлар*).
- Балалар, бу бит гади эзләр түгел икән, анда серле рәсемнәр ясалган, аларны иптәшләребезгә күрсәтмичә генә кararга кирәк, соңыннан нәрсә килеп чыкканын сүз белән әйтмичә генә күрсәтергә кирәк.

(***кара силует формасында ясалган рәсемнәрне пантомима ярдәмендә аңлатып күрсәтү***).

- Балалар, әйдәгез рәсемнәребез белән уйнап алабыз. Мин: “1,2,3 үз өеңә кайт”- дигәч йорт хайваннары өй ясалган рәсем янына, кыргый хайваннар урман рәсеме янына киләсез. (Уен азагында балаларга : “Син ни өчен монда бастың?- дигән сорау бирү).

Уен: “Үз өеңә кайт”

- Балалар, кем үзенең җәнлеге турыннда сөйләп күрсәтергә тели? (***теләгән баладан схема буенча сөйләтү***).

3) Машаның көлгән тавышы ишетелә.

- Балалар, Машаның сере бетмәгән бит әле. Әйдәгез карыйк әле тагын берәр сер яшерде микән әллә ул? Ромашка чәчәге табып алабыз (***аның тажларында табышмаклар***).

Җылы якта яши, ләкин арыслан түгел.
Аягы бар, кулы бар, ләкин кеше түгел.
Койрыгы озын, ләкин песи түгел.
Агачтан, агачтан сикерә, ләкин тиен түгел.

(Маймул)

Җылы якта яши, ләкин юлбарыс түгел.
Зур колаклы, ләкин чебурашка түгел.
Су ярата, ләкин крокодил түгел
Өзын борынлы, ләкин Буратино түгел.

(Фил)

Җылы якта яши, ләкин маймул түгел.
Тәне таплы- таплы, ләкин гепард түгел.
Өзын муенлы, ләкил ат түгел.

(Жираф)

Җәнлекләрнең сүрәтләре экранда күрсәтелә, "В мире животных" музыкасы яңгырый.

- Сезнең зоопаркка барганыгыз бармы? Зоопарк ни өчен кирәк?(*балаларның җаваплары*). Кешеләр үзләренең җирлегендә булаган төрле җәнлекләрне китаптагы рәсемнәрдән, телевизордан гына түгел, ә чынлыкта күрә алсыннар, алар турында бе лсеннәр, аларны өйрәнсеннәр өчен кирәк. Балалар, сез ничек уйлысыз җәнлекләргә кайда ныгырак ошый читлектәме, әллә иректәме? (*балаларның җаваплары*). Ләкин зоопаркның җәнлекләр өчен уңай ягы да күп. Анда җәнлекләргә интегеп ризык эзләп йөрергә кирәк түгел, аларны кешеләр ашаталар, аларга анда җылы, алар караулы.
- Балалар, сез үзегезне зоопаркта ничек тотарга кирәклеген беләсезме икән, әйдәгез тикшереп карык әле.

"Ярый ярамый" уены уйнатыла.

- Мин сезгә сораулар бирәм, ә сез "Әйе ярый" яки "Юк ярамый" – дип җавап бирерсез.

- Зоопаркта кычкырып, тавышланып йөрергә ярый.
- Зоопаркта хайваннарга сокланып карарга ярый.
- Зоопаркта хайваннарны ашатканны карап торырга ярый.
- Зоопаркта хайваннарны куркытып уйнарга ярый.
- Зоопаркта чисталык саклап йөрергә кирәк.

- Балалар, бәлки зооапркта үз- үзеңне тоту турында үзегезнең дә сорау бирәсегез киләдер?

- Зоопаркка үзең генә барырга ярыймы?
- Зоопаркта хайваннарны кулдан ашатырга ярыймы?
- Зоопаркта хайваннарны сыйпарга ярыймы?

- Булдырдыгыз, балалар, ә хәзер мин сезне үземнең зоопаркыма чакырам. (***Зоопарны карау***).

- Сезгә монда таныш җәнлекләр бармы? Аларга ашарга нәрсә бирәләр микән? ***Сезне шаккаттырган җәнлек турында кемнең сөйлисе килә***? Ә җәнлекләрне кайда тоталар? (***Балаларны вольер белән таныштыру, "Вольер" сүзен кабатлау***). Монда ничә җәнлек бар, ә ничә вольер буш?

Ах минем шаян җәнлекләрем качканнар бит, ә мин аларның кайда качканнарын беләм. Фил өстә, аның янында зур курчак бар. (Шул рәвешле арыслан, маймул, жираф табыла).

- Балалар ә хәзер әйдәгез әле зоопаркта яшәүче җәнлекләрнең яшәгән урыннарына барып кайтабыз *(уен алдыннан балаларга маймул, кенгуру, пингвин медальённары кигерелә)*.

"Летчики" җырлы уен башкарыла.

- Балалар, без сезнең белән бүген бик күп җәнлекләр турында сөйләштек. Сез алар турында китап ясыйсыгыз киләме. Мин сезгә менә мондый җәнлекләр төшкән матур битләр биреп чыгам,ә менә монда өстәлдә аларның ризыкларын куям, сез үзегезнең җәнлекнең нәрсә ашаганын эзләп табып үзегезнең җәнлегегез янына беркетеп куясыз. Ныгыту (*сораулар ярдәмендә*).

Балалар эше. Тәрбияче балаларның эшләрен берләштереп китап ясап эшне тәмамлый.

4) Машаның көлгән тавышы ишетелә.

- Балалар, кая качты микән соң бу Маша әйдәгез эзләп карыйк әле.

Балалар йокы бүлмәсеннән җәнлекләр ясанлган шарлар табалар.

- Карагыз әле Маша сезгә нинди матур бүләкләр җибәргән. Бигерәк шаян кыз булып чыкты бу Маша , үзе күренмәде, ә үзе безнең белән шундый күңелле итеп уйнады.
- Балалар, сезгә бүгенге очрашу ошадымы? Өйгә кайткач эти- әниләрегезгә нәрсә турында сөйләрсез микән?